МИНИСТЕРСТВО
ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ **БОЕРЫК**

03.09.2013 г.Казань № МК-23

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә бәйгеләр үткәрү турында

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының кадрлар составы белән эшләүне алга таба да камилләштерү максатларында, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы нигезендә Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының югары профессиональ кадрлар составы һәм кадрлар резервын булдыру максатларында боерык бирәм:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге уздыру турында нигезләмә (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатларга карата таләпләр (2 нче кушымта).

1.3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге (3 нче кушымта).

1.4. Бәйгедә катнашучыларны бәяләү билгеләре (4 нче кушымта).

2. Кадрлар бүлегенә (С.Н.Афанасьева) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә бәйгеләр үткәрү буенча бәйге комиссиясе эшчәнлеген;

2.2. бәйсез экспертлар белән эксперт хезмәтләре күрсәтүгә килешүләр төзүне.

3. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (О.В.Апрелева) бәйгеләр уздыру һәм Россия Федерациясе законнары һәм бәйгеләр уздыру өчен эксперт хезмәтләре күрсәтүгә төзелгән килешүләр нигезендә бәйсез экспертлар хезмәте өчен түләү белән бәйле чыгымнарны финанслау өчен акча бүлеп бирелүен тәэмин итәргә.

4. Оештыру эшләре бүлегенә (И.В. Галиева) үткәрелә торган бәйгеләрне мәгълүмати яктан тәэмин итәргә.

5. 2007 елның 19 мартындагы К-42 номерлы боерыкны үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Ю.Н.Багровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасары – министр **Р.А.Шәйхетдинов**

Татарстан Республикасы
мәгълүматлаштыру һәм
элемтә министрының 2013
елның 03.09.2013 № МК-23
боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге уздыру турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге уздыру буенча бәйге комиссиясенең (алга таба – бәйге комиссиясе) эшләү вакытлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә бәйге уздыру методикасы билгеләнә.

1.2. Нигезләмә Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (алга таба – граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы) бәйге үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге (алга таба – бәйге) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә тигез шартларда үтеп керүе буенча конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) бәйге нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.3. Бәйге Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында (алга таба – Министрлык) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясы һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты указы нигезендә уздырыла.

Бәйге граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва белдерүче затларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфаны биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.4. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә граждан хезмәтенең конкурс нигезендә биләнә торган вакантлы вазыйфасы булганда Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры (алга таба – Министр) карары нигезендә игълан ителә.

1.5. Министрлыкта бәйге түбәндәге очракларда үткәрелми:

1) Министрлыкта «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен билгеле бер чорга биләү өчен билгеләгәндә;

б) билгеле бер чорга хезмәт контракты төзелгәндә;

в) 2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1, 2 һәм 3 өлешләрендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

г) бәйге нигезендә төзелгән кадрлар резервында булган граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләгәндә.

1.6. 4. Бәйге уздырылмаска мөмкин:

а) алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы боерыгы нигезендә расланучы вазыйфалар исемлегендә аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

б) эшкә яллаучы затның карары нигезендә, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

объектив һөнәри әһәмиятле билгеләр нигезендә кандидатларны бәяләү;

бәйгеләрдә катнашучылар арасыннан, бәйге процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

2. БӘЙГЕ КОМИССИЯСЕ ТӨЗҮ ҺӘМ АНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлыкта бәйге уздыру өчен министр боерыгы белән бәйге комиссиясе төзелә.

2.2. Конкурс комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.2.1. Министрлыкта «җитәкчеләр» категориясендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге үткәрү буенча бәйге комиссиясен Министр җитәкли.

2.2.2. Граждан хезмәтенең башка вакантлы вазыйфаларын биләүгә бәйгеләр үткәрү өчен Министр боерыгы белән граждан хезмәте вазыйфаларының төрле категорияләре һәм төркемнәре өчен берничә бәйге комиссиясе төзелергә мөмкин.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырыш уздыру көнен билгели һәм аның көн тәртибен раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга кул куя. Комиссия рәисе булмый торганда, аның хокукларын һәм вазыйфаларын бәйге комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Бәйге комиссиясенең рәисе тарафыннан бәйге процедураларын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составы раслана.

Бәйге комиссиясенең сәркатибе комиссиянең эшен тәэмин итә (гаризаларны терки, кабул итә, эшләрне формалаштыра, беркетмәләр алып бара h.б.).

2.4. Комиссия составына министр урынбасарлары, Министрлык бүлекчәләренең җитәкчеләре: Министрлыкның кадрлар, хокукый тәэмин итү бүлекчәләре җитәкчеләре, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге үткәрелә торган структур бүлекчәсе җитәчесе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт граждан хезмәткәрләре эшләре буенча департамент вәкиле, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт граждан хезмәткәрләре эшләре буенча департамент тарафыннан Министр гаризасы буенча бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр рәвешендә экспертларның персональ белешмәләрен күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм бүтән оешмаларның вәкилләре кертелә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Граждан хезмәтенең вазыйфаи вәкаләтләрен үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вакант вазыйфасын биләүгә карата бәйге үткәрелгәндә бәйге комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Бәйге комиссиясенең составы, бәйге комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгать каршылыклары барлыкка килү ихтималлыгы булмаслык итеп төзелә.

2.7. Бәйге комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр дә анда аның әгъзалары саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар уздыру рөхсәт ителми.

2.9. Бәйге уздыру нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, бәйге комиссиясе рәисе тавышы хәл иткеч була. Бәйге комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән риза булмаган очракта, махсус фикерен белдерергә мөмкин, ул бәйге комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм бәйге комиссиясендәге әлеге әгъзаның имзасы белән беркетелә.

2.10. Бәйгедә катнашучыларга карата бәйге комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

а) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә аеруча туры килә, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү өчен тәкъдим ителә;

б) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә туры килә, тиешле кадрлар резервына керту өчен тәкъдим ителә;

в) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә туры килми.

2.11. Бәйге комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны граждан хезмәте вазыйфасына билгеләү яки кадрлар резервына керту яисә моннан баш тарту өчен нигез булып тора.

2.12. Бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиядә тавыш бирү нәтиҗәләре) бәйге комиссиясе беркетмәсе (белән нче кушымта) рәсмиләштерелә, анда рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм бәйге комиссиясе утырышында катнашкан бәйге комиссиясе әгъзалары кул куя.

2.13. Бәйге процедураларын, бәйге комиссиясе утырышлары беркетмәләрен эшләү һәм әзерләү буенча эш документларының эчтәлеге, бәйге биремнәрендәге сораулар һәм темалар исемлеге бәйге тәмамланганчыга кадәр хезмәттә файдаланыла торган мәгълүмат булып санала.

2.14. Бәйгене оештыру һәм бәйгене үткәрүне, бәйге комиссиясе эшен тәэмин итүне турыдан-туры оештыруны Министрлыкның кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

3. БӘЙГЕЛӘРДӘ КАТНАШУЧЫЛАР

3.1. Бәйгедә катнашуга Министрлыкның вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кандидатларга карата тиешле таләпләргә туры килә торган һәм билгеләнгән срокта кирәкле барлык документларны тапшырган гражданнар (алга таба кандидатлар дип атала) кертелә.

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларга карата таләпләр (боерыкка 3 нче кушымта) һәм Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатлар тарафыннан бирелә торган документлар һәм материаллар исемлеге (боерыкка 4 нче кушымта) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнгән.

3.2. Бәйгедә катнашу өчен документлар кандидатлар тарафыннан бәйге комиссияләренә бәйгене үткәрү турында мәгълүмати хәбәр «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырылган көннән соң 21 көнлек чорда тапшырыла.

3.3. Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру хөрмәткә лаек сәбәпләргә бәйле булганда, аларны тапшыру вакытлары күчерелергә мөмкин.

4. БӘЙГЕЛӘРНЕ УЗДЫРУ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Бәйге үткәрелгәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларына нигезләнгән бәйге биремнәре һәм процедуралары кулланыла, алар федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү билгеләре Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфаларына белдерелә торган квалификация таләпләренә туры китереп эшләнгән.

Бәйгедә катнашучыларны бәяләү билгеләренең үрнәк исемлеге һәм кыскача эчтәлеге шушы боерыкка 4 нче кушымтада китерелгән.

Бәйге үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә карап, бәйгедә катнашучыларны бәяләү билгеләре үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан бәйге биремнәрен үтәү һәм бәйге процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗәләр кандидатлар исемлегендәге балларның күләме рәвешендә күрсәтелә.

4.4. Бәйге ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Министрлык бәйгедә катнашу өчен документларны Министрлыкның рәсми сайтында кабул итү турында мәгълүмати хәбәр урнаштыра.

Бәйге уздыру турында урнаштырыла торган мәгълүмати хәбәрдә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының исеме, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга куела торган таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, бәйгене уздыру датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы белән расланган «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге турында» Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге турында нигезләмәнең 7 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, башка мәгълүмат материаллары күрсәтелә.

Бәйгенең беренче этабы бәйгене үткәрү турында Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмати хәбәр урнаштырылган көннән башлана һәм 21 көннән дә иртәрәк булмаган чорда тәмамлана.

4.4.2. Вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү, Министрлыкның кадрлар резервына кертү өчен кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшергәннән соң Министрлыкның кадрлар бүлеге документлар кабул итүне тәмамлаган көннән соң җиде көнлек чорда Министрга гражданнарны (граждан хезмәткәрләрен) бәйгедә катнашуга кертү турында карар кабул итү яки аларны бәйгедә катнаштырудан нигезле баш тарту турында тәкъдим кертә.

Кандидатларның тикшерелгән документлары һәм Министрлыкның кадрлар бүлегенең тәкъдиме Министрга бәйгенең икенче этабын уздыру турында карар кабул итү өчен тапшырыла.

4.4.3. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа кадрлар бүлеге тарафыннан бәйгедә катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача рәвештә хәбәр ителә.

4.4.4. Бәйгедә катнашуга кертелмәгән, вакант вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучы бу карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.4.5. Билгеләнгән таләпләргә туры килә торган ике һәм аннан күбрәк кандидатның булуы бәйгенең беренче этабын тәмамлау шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кадрлар бүлеге бәйгенең икенче этабы башланганчы 15 көн эчендә аны бәйгедә катнашуга кертелгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр җибәрә.

4.4.6. Бәйгенең икенче этабы өч төрле формада, бәйге игълан ителгән граждан хезмәте вазыйфалары төркеменә һәм категориясенә карап уздырылырга мөмкин.

А. Граждан хезмәтенең өлкән вазыйфаларына бәйге үткәрелгәндә, икенче этап кандидатлар биргән документларны анализлаудан һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре белән аерым әңгәмәләр уздырудан гыйбарәт.

Б. Граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларына бәйге уздырылганда икенче этапта түбәндәгеләр үткәрелә:

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларга анализ;

кандидатларның һөнәри белемнәрен ачыклау максатында аналитик эшләрне бәяләү;

структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре белән шәхси әңгәмәләр уздыру.

Аналитик эшне (реферат) кандидатлар бәйге уздырыла торган структур бүлекчәләр эшчәнлеге юнәлеше буенча әзерлиләр. Аналитик эшләрне (рефератларны) бәяләү өчен Министрлыкның тәкъдим ителгән кандидатлар белән аналитик эш (реферат) темасы белән бәйле өлкәдә эшләүче башка структур бүлекчәләре хезмәткәрләре җәлеп ителергә мөмкин.

Әлеге вазыйфалар төркеме өчен бәйгенең икенче этабында кандидатлар бәяләнгәндә, гамәлдәге федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми торган кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларына нигезләнгән бәйге биремнәре һәм процедуралары (компьютер яки бланк тесты) файдаланылырга мөмкин.

В. Икенче этап граждан хезмәтенең төп вазыйфаларына бәйге кандидатлар тарафыннан бирелгән документларны анализлаудан, структур бүлекчәләр эшчәнлеге юнәлешләре буенча аналитик эшләрне (рефератларны) бәяләүдән, шулай ук Министрлык җитәкчелеге белән шәхси әңгәмәләр нәтиҗәләрен бәяләүдән гыйбарәт.

Вазыйфаларның әлеге төркеме өчен рәсми методикаларның (тестларның) үтәлеше нәтиҗәләрен анализлау нигезендә, шулай ук төркем дискуссияләре һәм махсус биремнәр барышында кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү уздырыла. Биремнәрнең характеры һәм кандидатларга тәкъдим ителә торган төркем дискуссияләренең темасы, булачак һөнәри эшчәнлеккә бәйле, экспертлар тәкъдимнәре нигезендә эшләнә һәм бәйге комиссиясе тарафыннан раслана.

4.4.7. Кандидатларга тест сынаулары компьютер формасында уздырыла. Бәйге комиссиясе дәгъва белдерүчеләргә тест сынаулары өчен сораулар исемлеген төзи, шулай ук дөрес булмаган җавапларның чик исәбен (яисә процентын) раслый. Дөрес булмаган җавапларның рөхсәт ителгән исәбе 25 проценттан артык була алмый.

Сораулар исемлеге гомуми танышу өчен мөмкин булырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә һәм бәйгедә катнашучының түбәндәгеләрне белүен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен;

федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын;

дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын;

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турында нигезләмәне;

граждан хезмәте вакант вазыйфасының вазыйфаи регламентын;

структур бүлекчә эшчәнлеге юнәлеше буенча норматив хокукый актларны h.б.

Тестта иң күбе 50 сорау булырга тиеш.

Дөрес җаваплар тигез санда булганда, катнашучыларга җавап бирү өчен вакыты билгеләнеп, өстәмә тестлар бирелә.

4.4.8. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә бәйге комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук әлеге Нигезләмәдә һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

4.4.9. Дәгъва белдерүчеләрнең һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәйге комиссиясе әгъзалары кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан һәр бәйгегә әзерләнә торган бәяләү кәгазьләрендә билгели.

4.4.10. Бәйге башланыр алдыннан турыдан-туры бәйге комиссиясе утырышына рәислек итүче зат бәйге комиссиясе әгъзаларына аны уздыру, билгеләр кую тәртибе турында, бәйге комиссиясе әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары турында инструктаж уздыра.

4.4.11. Бәйге комиссиясенең һәр әгъзасы бәйге комиссиясе сәркатибеннән бәйгедәге барлык катнашучыларга бәяләү кәгазьләрен ала һәм тиешле баллар куя. Һәр бәяләү кәгазендә гомуми баллар исәбен куйганнан соң, бәйге комиссиясе әгъзасы бәяләү кәгазьләрен имзалый һәм аларны бәйге комиссиясе сәркатибенә тапшыра.

4.4.12. Бәяләү кәгазьләре нигезендә бәйге комиссиясе сәркатибе бәйгедә һәр катнашучы алган нәтиҗә балларын куша.

Бәяләү кәгазенә төзәтмәләр кертү рөхсәт ителми.

Кандидатларны бәяләү нәтиҗәләре анкетага кертелә (2 нче кушымта).

4.5. Икенче этапның нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта бәйгенең йомгаклау нәтиҗәләре булып граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча кандидатларның бәйге комиссияләре тарафыннан әзерләнгән рейтинглары тора.

Бәйге йомгакларын ясау һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кандидат турында карар кабул итү нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

бәяләү билгеләре буенча кандидатлар тарафыннан барлык бәйге процедураларын алу нәтиҗәләре буенча тупланган балларның суммалары;

кандидатлар шундагы вазыйфага дәгъва белдерә торган структур бүлекчә җитәкчеләренең кандидатлар белән әңгәмә (әңгәмәләр) уздыру йомгаклары буенча фикере (Министрлык җитәкчелегенең фикере).

Бәйге комиссиясе бәйгедә җиңүче турында карарлар, шулай ук Министрлыкның кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлекләрен раслый.

4.6. Бәйгене уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең аны биләү өчен бәйге игълан ителгән вакантлы вазыйфасы буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, бәйге комиссиясе өстәмә бәйге сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа бәйге уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.7. Министр яңа бәйге уздыру турында яки бәйгедә катнашкан, вакантлы вазыйфаны биләү өчен белдерелә торган таләпләргә аеруча туры килә торган һәм иң күп баллар санын туплаган затны мөмкин булганча иң зур сынау чоры белән вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына билгеләү турында карар кабул итә.

4.8. Әгәр бәйгедә катнашучы ике яки аннан күбрәк затлар тигез сандагы балларны тупласа, бәйге комиссиясе рәисенең фикере хәл иткеч була.

4.9. Бәйгене үткәрү нәтиҗәләре буенча 10 көн эчендә бәйге комиссиясе карары кабул ителә, ул беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм бәйге комиссиясе утырышына рәислек итүче зат, бәйге комиссиясе сәркатибе һәм бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.10. Бәйге нәтиҗәләре нигезендә бәйгедә җиңүчене дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында Министр боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – бәйгедә җиңүчене кадрлар резервына кертү, тиешле язуны граждан хезмәткәренең шәхси эшләренә һәм граждан хезмәткәренең хезмәт эшчәнлеген раслый торган бүтән документларга кертеп, Министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Бу вакытта вазыйфалар номенклатурасы нигезендә, бәйгедә җиңүчене вазыйфага билгеләү өчен тәкъдим иткәндә, Министрга мәҗбүри тәртиптә бәйге комиссиясе тарафыннан мондый карарны кабул итүгә нигез булып хезмәт иткән бәйге комиссиясе карары һәм материаллар кертелә.

4.11. Вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына билгеләүдән кандидатны кире кагу очрагында аңа Министрлыкның кадрлар резервында тиешле вазыйфа

тәкъдим ителергә мөмкин. Граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва белдеүче Россия Федерациясе законнары нигезендә бәйге комиссиясе карарына шикаять белдерергә хокуклы.

4.12. Бәйгедә катнашкан кандидатларга кадрлар бүлеге бәйге нәтиҗәләре турында язма рәвештә бәйге тәмамланган (бәйге комиссиясе карары кабул ителгән) көннән алып җиде көн эчендә хәбәр итә.

Бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бәйге тәмамланган көннән алып җиде көн эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.13. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин бәйгедә катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм бәйгедә катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча бәйге тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.14. Бәйгедә катнашу (бәйгене үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны яшәү өчен алып тору, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану h.б.) белән бәйле чыгымнар катнашучылар тарафыннан үз акчалары исәбеннән түләнә.

Татарстан Республикасы
мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрының 2013 елның
03.09.2013 № 17П-23
боерыгына 2 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫНДА ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БИЛӘҮ ӨЧЕН КАНДИДАТЛАРГА КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

1. Гомуми таләпләр

1.1. 18 яшьтән кечерәк булмаган, Россия Федерациясе дәүләт телен белгән, федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларында билгеләнгән, дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазифасын биләү өчен кирәкле таләпләргә җавап бирә торган Россия Федерациясе гражданнары конкурста катнашу хокукына ия.

1.2. Гражданин түбәндәге очракларда конкурста катнашуга кертелми:

а) аны законлы көченә кергән суд карары нигезендә хезмәткә яраксыз яки эшкә яраклылык сәләте чикләнгән дип таныганда;

б) законлы көченә кергән суд карары белән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны башкару мөмкинлеген юкка чыгара торган җәзага хөкем ителгәндә, шулай ук үзенә карата федераль законда билгеләнгән тәртиптә алынмаган яки капланмаган суд хөкеме булганда;

в) дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасын үтүдән баш тартканда, әгәр дә граждан биләү өчен дәгъва кыла торган гражданлык хезмәте вазифасы яки гражданлык хезмәткәре били торган гражданлык хезмәте вазифасы буенча вазифаи бурычларны башкару мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса;

г) граждан хезмәтенә керү яки аны үтәү буенча каршылык тудыра торган һәм медицина оешмасы бәяләмәсе белән расланган авыруы булганда. Диспансерлаштыру узу тәртибе, мондый авырулар исемлеге һәм медицина учреждениесе бәяләмәсенең рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә;

д) гражданлык хезмәткәре белән якын туганлыкта яки үги туганлыкта (ата-анасы, тормыш иптәше, балалары, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук тормыш иптәшенең ир туганнары, кыз туганнары, ата-анасы, балалары һәм балаларының тормыш иптәшләре) торганда, әгәр дә гражданлык хезмәте вазифасын биләү беренчесенең икенчесенә турыдан-туры буйсынуына яки контрольлегендә булуына бәйле булса;

е) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яки башка дәүләт

гражданлыгын алу;

ж) башка дәүләт (башка дәүләтләрнең) гражданлыгына ия булу, әгәр дә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкача каралмаган булса;

з) гражданлык хезмәтенә кергәндә ялган документлар яки белә торып ялган белешмәләр тапшырганда;

и) граждан хезмәтенә кергәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында әлеге Федераль законда билгеләнгән белешмәләрне тапшырмаганда яисә белә торып ялган белешмәләр тапшырганда;

к) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны үтәмәүгә һәм әлеге Федераль законда, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәшү максатларында билгеләнгән вазыйфаларны башкармауга бәйле очракларда граждан хезмәткәренә карата эшкә алучы вәкиленең ышаныч югалтуы.

2. Квалификация таләпләре

2.1. Белемгә һәм дәүләт хезмәте стажына яисә эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре:

дәүләт хезмәтенең төп вазыйфалары – югары һөнәри белем булу, әйдәп баручы яисә өлкән дәүләт вазыйфаларында кимендә ике еллык дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек буенча кимендә өч еллык эш стажы;

дәүләт хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалары – югары һөнәри белем, өлкән һәм кече дәүләт вазыйфаларында кимендә бер еллык дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек буенча кимендә ике еллык эш стажы булу;

дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» категориясендәге өлкән вазыйфалар – стажына карата таләпләр куелмыйча, югары һөнәри белемгә ия булу;

дәүләт хезмәтенең «тәэмин итүче белгечләр» категориясенең өлкән вазыйфалары һәм кече вазыйфалары – эшчәнлек юнәлеше буенча урта һөнәри белем булу, стажга таләпләр куймыйча.

2.2. Вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламенты һәм Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре турында» 2006 елның 17 августындагы К-119/03-02 номерлы боерыгы белән билгеләнгән.

Татарстан Республикасы
мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрының 2013 елның 03.09.2013
№ 17-К-23 боерыгына 3 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫНДА ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БИЛӘҮ ӨЧЕН КАНДИДАТЛАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры исеменә шәхси гариза (1 нче кушымта).

2. Кандидатның шәхесен таныклый торган документ күчермәсе (паспорт, хәрби билет, шәхес таныклыгы).

3. Үз куллары белән тутырылган һәм 4 х 6 үлчәмендәге 2 фото белән имзаланган анкета (2 нче кушымта).

4. Һөнәри белем алу турында, шулай ук гражданның теләгенә карап – өстәмә белем алу, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турындагы документларның нотариаль яктан яки эшләү (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре.

5. Хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш) яисә гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар.

6. Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә һәм муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны узуга тоткарлык ясый торган авыру барлыгы (булмавы) турында медицина учреждениесе бәяләмәсе (№001-ГС/у исәп формасы), ул Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган.

Искәрмә:

Конкурста катнашу теләген белдергән, дәүләт органында граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре гаризаны эшкә яллаучы вәкиле исеменә тапшыра.

Башка дәүләт органында конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре шул дәүләт органына эшкә алучы вәкиле исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырылган, имзаланган һәм үзенең граждан хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган анкетаны фотосын теркәп тапшыра.

Татарстан Республикасы
мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрының 2013 елның
_____ № _____
боерыгы белән расланган Исемлеккә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-
министры урынбасары – Татарстан
Республикасы мәгълүматлаштыру һәм
элемтә министрына
_____

кемнән_____
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Яшим:_____
_____
Тел. _____
_____
(эшнеке, өйнеке)

ГАРИЗА

Мине Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурста катнашырга кертүне сорыйм, – түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен:

_____
(вазыйфа атылышы)
_____
(бүлекчәнең аталышы)

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә белән, шул исәптән вакант вазыйфага карата белдерелә торган квалификация таләпләре белән таныштырылдым.

Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасы үткәрелү белән килешәм.

Гаризага терким: (теркәлә торган документларны санап чыгарга).

_____ _____ _____
(дата) (имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы
мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрының 2013 елның
_____ № _____
боерыгы белән расланган
Исемлеккә 2 нче кушымта

АНКЕТА
(үз кулы белән тутырыла)

Фотолар өчен
урын

1. Фамилия _____
   Исем _____
   Ата исеме _____

2. Әгәр фамилия, исем яки ата исеме үзгәртелгән булса, аларны, шулай ук кайчан һәм ни сәбәпле үзгәртелүе хакында да күрсәтегез.	
3. Туган көн, ай, ел һәм урын (сала, авыл, шәһәр, район, өлкә, край, республика, ил).	
4. Гражданлык (әгәр үзгәрткән булсагыз, кайчан һәм ни сәбәпле үзгәртелүен күрсәтегез, башка дәүләт гражданлыгына ия булсагыз – күрсәтегез)	
5. Белеме (кайчан һәм нинди уку йортларын тәмамлаган, дипломнар номерлары) Әзерлек юнәлеше яки белгечлеге буенча диплом Диплом буенча квалификация	
6. Югары уку йортыннан соңгы һөнәри белем: аспирантура, адъюнктура, докторантура (белем бирү яки фәнни учреждениенең исеме, уку елы) Гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем (кайчан бирелгән, дипломнарның, аттестатларның номерлары)	
7. Нинди чит телләрне һәм Россия Федерациясе халыклары телләрен беләсез һәм ни дәрәҗәдә (сүзлек белән укыйсыз һәм тәрҗемә итәсез, иркен укыйсыз һәм аңлашасыз)	
8. Федераль граждан хезмәтенең класслы чины, дипломатик ранг, хәрби яки махсус исем, хокук саклау хезмәтенең класслы чины, Россия Федерациясе граждан хезмәтенең класслы чины,дәүләт хезмәтенең квалификацияле разряды(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)	
9. Сезнең суд хөкеменә тартылганыгыз булдымы (кайчан һәм ни өчен)	

10. Эшләү, хезмәт итү, белем алу чорында рәсмиләштерелгән дәүләт сереннән файдалану мөмкинлеге, аның формасы, номеры һәм датасы (булган очракта)	

11. Хезмәт эшчәнлеге башланган бирле башкарыла торган эш (югары һәм урта махсус белем бирү йортларында укуны, хәрби хезмәтне, бер үк вакытта икенче эштә эшләүне, эшкуарлык эшчәнлеген һ.б. кертеп).
Әлеге пунктны тутырганда оешмаларны үзләре гамәлдә булган вакытта аталган кебек атарга, хәрби хезмәт турында хәрби частьнең номерын һәм вазыйфаны күрсәтеп язарга кирәк.

Ае һәм елы		Оешма аталышын күрсәтеп вазыйфасы	Оешманың адресы (ш.и. чит илдә)
керү	китү		

12. Дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр һәм аерымлык билгеләре
_____
_____

13. Сезнең иң якын туганнарыгыз (әти, әни, ир туганнар, кыз туганнар һәм балалар), шулай ук ирегез (хатыныгыз). шул исәптән элеккеге.
Әгәр туганнарыгыз фамилияләрен, исемнәрен, ата исемнәрен үзгәрткән булсалар, шулай ук аларның элеккеге фамилияләрен, исемнәрен, ата исемнәрен күрсәтергә кирәк.

Туганлык дәрәҗәсе	Фамилиясе, исеме, атасының исеме	Туу елы, көне, ае һәм урыны	Эш урыны (оешманың исеме һәм адресы), вазыйфа	Өй адресы (теркәлү, фактик яшәү урыны)

14. Сезнең якын туганнарыгыз (әти, әни, абыйлар, сеңелләр һәм балалар), шулай ук ирегез (хатыныгыз), шул исәптән чит илдә даими яшәүче һәм (яисә) башка дәүләткә даими яшәү урынына чыгу өчен документлар рәсмиләштерүче элеккеге туганнар _____
_____
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, кайсы вакыттан бирле чит илдә яшиләр)
15. Чит илдә тору (кайчан, кайда, нинди максат белән) _____

_____
_____
_____
16. Хәрби хезмәткә мөнәсәбәт һәм хәрби исем _____
_____
17. Өй адресы (теркәлү адресы, фактта яшәү), телефон номеры (яки башка элемтә төре)
_____
_____
_____
_____
_____
18. Паспорт яки аны алмаштыра торган документ _____
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
19. Чит ил паспортының булуы _____
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
20. Мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенең иминият таныклыгы номеры (булган очракта)
_____
21. ИНН (булган очракта) _____
22. Өстәмә белешмәләр (сайлаулы вәкиллекле органнарда катнашу, үзегез хакында хәбәр итәргә теләгән башка мәгълүмат) _____
_____
_____
_____
23. Белә торып үзем турында анкетада хәбәр ителгән ялган белешмәләр һәм минем квалификация таләпләренә туры килмәвем конкурста катнашудан һәм вазыйфага алынудан мәхрүм ителүемә китерергә мөмкин булуы турында миңа мәгълүм.

Миңа карата тикшерү чараларының уздырылуына риза.

«__»_____ 20__ ел. Имза _____

Мөһер урыны Рәсмиләштерелә торган затның фотосы һәм хезмәт эшчәнлеге, хәрби хезмәт һәм белеме турындагы белешмәләр шәхесне раслаучы документларга, хезмәт кенәгәсендәге язмаларга, алган белем һәм хәрби хезмәт турындагы документларга туры килә.

«__» _____ 20__ ел. _____
(кадрлар хезмәте хезмәткәренең имзасы һәм фамилиясе)

Татарстан Республикасы
мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрының 2013 елның
_____ № _____
боерыгына 4 нче кушымта

БӘЙГЕЛӘРДӘ КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ БИЛГЕЛӘРЕ

1. Дәүләт хезмәте культурасына туры килүе

1.1. Һөнәри максатчанлыгы

Дәүләт хезмәтендә һөнәрдә шәхси потенциал үстерүгә омтылуы, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәттә үсүне күздә тотуы.

1.2. Гражданлык позициясе

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен саклау принципларын үтәү.

1.3. Һөнәри позициядәге активлыгы

Куелган мәсьәләләрне хәл иткәндә инициатива күрсәтергә омтылуы; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен хәлдән килгәнчә тырышлык күрсәтергә әзер булуы, физик һәм эмоциональ басым шартларында нәтиҗәле эш-гамәл кылуга (стрессларга каршы торуга) сәләтле булуы.

1.4. Үз-үзен үстерүгә әзер булуы

Үз белемнәреңне, осталыкларыңны һәм күнекмәләреңне даими камилләштерергә, карашларыңны киңәйтергә, катнаш һөнәр өлкәләрендә белемнәр һәм тәҗрибә алырга омтылу.

2.Дәүләт хезмәткәренең һөнәри вәкаләтлелеге

2.1. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә һөнәри белем дәрәҗәсе, юнәлеше һәм сыйфаты.

2.2. Һөнәри тәҗрибәсе

Тиешле һөнәр өлкәсендәге эшчәнлек итү озынлыгы һәм үзенчәлекләре; һөнәри эшчәнлегендә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүе; карьерасының үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәре, осталыгы һәм күнекмәләре

Тиешле өлкәдә, вазыйфаи бурычларны нәтиҗәле үтәү мөмкинлеген бирә торган һөнәри белемнәренең дәрәҗәсе; һөнәри эшчәнлекне регламентлый торган Россия Федерациясе законнарын белүе; заманча һөнәри технологияләр белән эш итә белүе.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләре

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыра торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютер белү, гомуми грамоталылык, чит телләр белү һ. б.).

3. Дәүләт хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитикага бәйле сәләтләре

Катлаулы мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген бирә торган, мәгълүматны анализлауны һәм структуралаштыруны таләп итүче системалы һәм сыгылмалы фикерләү дәрәҗәсе; яңа, гадәти булмаган чишелешләрне табуга сәләтле булуы.

3.2. Нәтиҗәле коммуникацияләү күнекмәләре

Эшлекле сөйләм этикасын саклавы; үз фикерен дәлилләп яклау һәм оппонентларны ышандыру сәләте; эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләренә ия булуы.

3.3. Җаваплылыгы

Карарларны кабул итүдә нигезле һәм мөстәкыйль эш итүе; нәтиҗәгә ирешүдә үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булуы.

3.4. Оештыруга бәйле сәләтләре

Үз эшчәнлегеңне һәм сиңа буйсынып эшләүчеләр эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, вазыйфаларны, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлеп бирү хисабына нәтиҗәләргә ирешә белү.

МИНИСТЕРСТВО
ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ **БОЕРЫК**

30.11.2016 г.Казань № П-246

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонаның экспертлар советы турында» 2016 елның 30 ноябрендәге П-246 номерлы боерыгы

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналары турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясының 10 өлеше, Махсус икътисадый зонасы белән идарә итү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыру турында 2016 елның 5 сентябрендәге С-577-АЦ/Д14 номерлы килешү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территориясендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисад зонасы белән идарә итүгә вәкаләт алган орган итеп билгеләү турында» 2016 елның 8 октябрендәге 728 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының экспертлар советын (алга таба – экспертлар советы) булдырырга.

2. Экспертлар советы (1 нче кушымта) һәм аның составы (2 нче кушымта) турында нигезләмә расларга.

3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонаның экспертлар советы турында» 2016 елның 19 октябрендәге П-218 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Бу боерык аңа имза салган вакыттан башлап үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Премьер министры
урынбасары – министр

Р.А. Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2016 елның 30 ноябрендәге П-246 номерлы боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының экспертлар советы турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонаның экспертлар советы (алга таба – экспертлар советы) коллегиаль орган булып тора һәм даими нигездә эшли.

2. Экспертлар советының шәхси составы Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы боерыгы белән раслана.

II. Экспертлар советының вәкаләтләре

3. «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә экспертлар советы:

а) Федераль законның 13 статьясы нигезендә махсус икътисадый зона резиденты статусын алырга ниятләгән затлар тарафыннан тапшырылган бизнес-планнарны бәяли һәм бизнес-планны бәяләү нәтиҗәләре буенча бизнес-планны хуплау турында яисә бизнес-планны хуплаудан баш тарту турында карар кабул итә;

б) махсус икътисадый зона резиденты статусын алырга ниятләүче һәм эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гариза биргән затка Федераль законның 13 статьясындагы 12 өлеше нигезендә бизнес-планга үзгәрешләр кертү буенча бер яисә берничә йөкләмә үтәлешен йөкләү турында карар кабул итә;

в) махсус икътисадый зона резидентының бизнес-планны үзгәртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү шартларын үзгәртү хакында гариза белән мөрәҗәгать итүе нигезендә Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлеше нигезендә бизнес-планга ярдәм итү турында яисә бизнес-планны хуплаудан баш

тарту турында, шулай ук Федераль законның 18 статьясындагы 5 өлеше нигезендә мондый резидентка бизнес-планга үзгәрешләр кертү буенча бер яисә берничә йөкләмәне үтәү йөкләмәсен бирү турында карар кабул итә;

г) Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасында фәнни-техник продукция җитештерү турында карар кабул итә.

III. Экспертлар советының составы һәм аның эшен оештыру

4. Экспертлар советы составына федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, шулай ук коммерциячел һәм коммерциясез оешмалар вәкилләре керә.

5. Экспертлар советы экспертлар советы рәисеннән, сәркатиптән һәм экспертлар советы әгъзаларыннан тора. Экспертлар советының гомуми саны 7 кешедән дә ким булмаска һәм 20 кешедән артмаска тиеш. Экспертлар советы рәисе Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

6. Экспертлар советы утырышларына материаллар әзерләү өчен, экспертлар советы рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан экспертлар советы әгъзалары белән бергә экспертлар советы составына керми торган экспертлар да җәлеп ителергә мөмкин булган эшче төркемнәр төзелергә мөмкин.

7. Экспертлар советы карарлары кирәк булганда үткәрелә торган утырышларда кабул ителә.

Экспертлар советы утырышы, әгәр анда билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән экспертлар советы әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булса, хокуклы дип санала.

Экспертлар советы утырышын экспертлар советы рәисе алып бара яисә, экспертлар советы әгъзалары булмаган очракта, утырышта рәислек итүче билгеләнә.

8. Экспертлар советы карарлары утырышта катнашучы экспертлар советы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, экспертлар советы рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Экспертлар советының һәр әгъзасы экспертлар советы утырышында аерым фикер белдерергә яисә язма рәвештә экспертлар советы утырышы беркетмәсендә чагылдырыла торган аерым фикер белдерергә хокуклы.

9. Экспертлар советы карарлары читтән торып тавыш бирүне уздыру юлы белән (сораштыру юлы белән) турыдан-туры очрашуны уздырмыйча кабул ителергә мөмкин. Әлеге Нигезләмә максатларында турыдан-туры очрашу дигәндә аны уздыру урынында экспертлар советы әгъзаларының хакыйкый рәвештә бергәләп катнашуы яки җыелыш уздыру урынында конференция-элемтә ярдәмендә яисә экспертлар советының барлык әгъзаларына реаль вакыт режимында бер-берсен күрергә һәм ишетергә мөмкинлек бирә торган башка ысул

белән оештырылган экспертлар советы әгъзаларының уртак җыелышуы турында сүз бара.

10. Экспертлар советы карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Экспертлар советы утырышларын уздыру йомгаклары буенча уртак җыелыш (турыдан-туры очрашу) рәвешендә беркетмәләр утырышта катнашкан экспертлар советының барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм экспертлар советы рәисе тарафыннан раслана.

Экспертлар советы утырышларын читтән торып тавыш бирү (сораштыру юлы белән) рәвешендә уздыру йомгаклары буенча беркетмәләр экспертлар советы рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана; бюллетеньнәр (сораштыру битләре) беркетмәгә теркәлә.

11. Экспертлар советы карарлары Федераль законда билгеләнгән чорларда Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына җибәрелә.

12. Экспертлар советының эш регламенты экспертлар советы тарафыннан раслана.

13. Экспертлар советы эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2016 елның 30 ноябрендәге П-246 номерлы боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонаның экспертлар советы составы

Шәйхетдинов Роман Александрович	Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры, экспертлар советы рәисе
Автушенко Евгений Владимирович	«Махсус икътисадый зоналар» акционерлык җәмгыятенең проектлар белән идарә итү һәм инвесторлар белән эшләү департаменты директоры (килешү буенча)
Афанасьев Михаил Павлович	Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы башлыгы (килешү буенча)
Әхмиева Эльмира Әхтәм кызы	Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Төбәк үсеше департаменты директоры урынбасары (килештерү буенча)
Вандюков Дмитрий Владимирович	Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының беренче урынбасары
Дьячков Виктор Васильевич	«АйСиЭл-КПО ВС» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)
Зверков Владимир Игоревич	Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының махсус икътисадый зоналарны булдыру һәм стратегик үстерү бүлеге башлыгы (килешү буенча)
Зыятдинов Марат Галимҗан улы	Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгы (килешү буенча)
Милявский Виталий Владимирович	«Махсус икътисадый зоналар» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)
Миңнуллина Талия Илгиз кызы	Татарстан Республикасының Инвестиция үсеше агентлыгы җитәкчесе (килешү буенча)
Носов Игорь Николаевич	«Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)
Святов Максим Александрович	Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының Халыкара хезмәттәшлек департаменты киңәшчесе (килешү буенча)
Семенихин Кирилл Владимирович	«Иннополис университеты» автономияле коммерциясез югары белем бирү оешмасы директоры (килешү буенча)

Хаҗиәхмәтов Булат Зөфәр улы	Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары (килешү буенча)
Хөсәенов Алмаз Шәүкәт улы	Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары (килешү буенча)
Шәгалиев Руслан Ринат улы	«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча)

МИНИСТЕРСТВО
ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ **БОЕРЫК**

09.11.2016 г.Казань № ПК-283

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә бәйгеләр уздыру турында» 2014 елның 05 сентябрендәге ПК-19 номерлы боерыгына үзгәрешләр керту турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә бәйгеләр уздыру турында» 2014 елның 05 сентябрендәге ПК-19 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче кандидатларга таләпләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә җавап бирмәвенә бәйле рәвештә, шулай ук граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләмәләре булу сәбәпле, гражданин (граждан хезмәткәре) бәйгедә катнашуга кертелми.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Квалификация таләпләре

2.1. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификацион таләпләр граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламенты белән билгеләнгән.

Белемгә һәм дәүләт хезмәте стажына яисә эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре.

Граждан хезмәтенең иң югары һәм төп вазыйфалар төркемнәрендә «җитәкчеләр», «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)», «белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен белгеч, магистратура дәрәҗәсеннән түбән булмаган югары белемгә ия булу мәҗбүри.

Граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендә «җитәкчеләр», «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге, граждан хезмәтенең әйдәүче һәм өлкән төркемнәренең «белгечләр» категориясендәге, шулай ук граждан хезмәтенең төп һәм әйдәүче төркемнәренең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен югары белемгә ия булу мәҗбүри.

Граждан хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрендә «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белемгә ия булу мәҗбүри.

Граждан хезмәте стажына яки белгечлек, граждан хезмәткәрләре өчен әзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

граждан хезмәте вазыйфаларының төп төркеменә керүче барлык категория граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – әйдәп баручы яки өлкән төркем вазыйфаларында кимендә ике еллык граждан хезмәте стажы яисә белгечлек, юнәлеш буенча эш стажы кимендә өч ел;

граждан хезмәтенең барлык категорияләрендәге вазыйфаларны биләү өчен – граждан хезмәтенең өлкән яки кече төркеме вазыйфаларында бер елдан да ким булмаган граждан хезмәте стажы яисә белгечлек, юнәлеш буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы.

Граждан хезмәтенең өлкән һәм кече вазыйфалар төркемнәрендә граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен граждан хезмәте стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

Граждан хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында тиешле вазыйфаи төркемнәр һәм аларга тиңләштерелгән хәрби һәм хокук саклау хезмәте вазыйфаларында, шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрдә муниципаль хезмәт вазыйфаларында эш стажы исәпкә алына.

2.2. Вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре турында» 2006 елның 17 августындагы К-119/03-02 номерлы боерыгы һәм граждан хезмәткәренең Вазыйфаи регламенты белән билгеләнгән.».

2. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә бәйгеләр уздыру турында» 2014 елның 05 сентябрендәге ПК-19 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә

министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы федераль законда, бүтән федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган материаллар һәм документлар.».

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасары – министр Р.А.Шәйхетдинов